ГЛАВА
КУГАРЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422662, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район,
с.Кугарчино, ул.Советская, дом 62А,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮГӘРЧЕН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

422662,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Күгәрчен авылы,
Совет урамы, 62А йорт,

**Тел.: (8-4361) 28-589 , факс: (8-4361) 28-589 , эл.адрес: Kugar.Rs@tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

. 2019 елның 23 октябре Кугәрчен авылы № 2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Кугәрчен авыл җирлегенең Зәнгәр-Күл авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Кугәрчен авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 14.1 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Кугәрчен авыл җирлегенең Зәнгәр-Күл авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2019 елның 19 ноябрендә 14сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Кугәрчен авыл җирлегенең Кугәрчен авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1.Күгәрчен, Зәнгәр- Күл авылларына янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;

2.Күгәрчен авылында Гагарин, Гиниятуллин, Жданов урамнары буйлап, вак таш сатып алу, юлланы ремонтлау;

3. Күгәрчен авылында су торбалары ремонтлау

4. Күгәрчен, Зәнгәр- Күл авылларында юлларны кышкы чорда карап тору:

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

6. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Күгәрчен авылы, Совет урамы,62А йорт; Зәнгәр- Күл авылы, Тукай урамы, 3А йорт; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы А.Т.Сафин